Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами `тыңлаулар бәяләмәсе

Арча шәһәре 05.08.2019

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына Арча шәһәре Советының 12.07.2019 ел, №123 карары белән расланган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турында фикер алышкач, гавами тыңлауларда катнашучылар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының тәкъдим ителгән проекты «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ нигезендә әзерләнгәнлегeн билгеләп үттеләр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гавами тыңлауларда катнашучылар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын хуплыйлар һәм Устав проектын әзерләү буенча эшче төркемгә, кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, Арча шәһәр Советының чираттан тыш утырышы каравына Арча шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын кертергә тәкъдим итәләр.

Секретариат җитәкчесе: Нигъмәтҗанова Г. Х.

Секретариат әгъзалары: Ильина Л. Ю.

Сабирова Э. Р.